**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Об отмене карантина, установленного на территории деревни Фадеевка Спасского района Республики Татарстан и на отдельных территориях Республики Татарстан в связи с их неблагополучием по заболеванию бешенством животных

В связи с истечением двух месяцев со дня последнего случая заболевания животных бешенством и выполнением противоэпизоотических и профилактических мероприятий, в соответствии со статьей 3[1] Закона Российской Федерации от 14 мая 1993 года № 4979-I «О ветеринарии» **постановляю**:

1. Отменить карантин, установленный в связи с неблагополучием по заболеванию бешенством животных:

а) на территории деревни Фадеевка Спасского района Республики Татарстан;

б) на следующих отдельных территориях Республики Татарстан:

улица Ленина в селе Ромодан Алексеевского района;

улица Тукая в селе Ключи-Сап Атнинского района;

улица Строителей в поселке городского типа Балтаси Балтасинского района;

улица Асылъяр в жилом массиве Киндери города Казани;

улица Вокзальная в городе Нижнекамске;

улица Юбилейная в селе Большое Афанасово Нижнекамского района.

2. Признать утратившими силу:

Указ Президента Республики Татарстан от 15 октября 2014 года № УП-985 «Об установлении карантина на территории деревни Фадеевка Спасского района Республики Татарстан и на отдельных территориях Республики Татарстан в связи с их неблагополучием по заболеванию бешенством животных»;

Указ Президента Республики Татарстан от 17 октября 2014 года № УП-994 «Об установлении карантина на отдельной территории Атнинского района Республики Татарстан в связи с ее неблагополучием по заболеванию бешенством животных».

3. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ *
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань,Кремль
20 декабря 2014 года
№ УП-1159

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Спас районының Фадеевка авылы территориясендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле урнаштырылган карантинны бетерү турында**

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә:

а) Татарстан Республикасы Спас районының Фадеевка авылы территориясендә;

б) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә:

Алексеевск районының Ромодан авылында Ленин урамы;

Әтнә районының Ключи-Сап авылында Тукай урамы;

Балтач районының Балтач шәһәр тибындагы поселогында Төзүчеләр урамы;

Казан шәһәренең Киндери торак массивында Асылъяр урамы;

Түбән Кама шәһәрендә Вокзал урамы;

Түбән Кама районы Олы Афанас авылында Юбилей урамы.

2. Түбәндәгеләр үз көчләрен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Спас районының Фадеевка авылы территориясендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2014 елның 15 октябрендәге ПУ-985 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Әтнә районының аерым территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2014 елның 17 октябрендәге ПУ-994 номерлы Указы.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2014 ел, 20 декабрь
№ ПУ-1159